| | | |
|---|---|---|
| ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

15.11.2022 Казан ш. № 404-120/кс-2022

«Менделеевск муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалыгы идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе өчен эчәргә яраклы суга 2023 елга тарифлар билгеләү турында

«Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу турында» 2011 елның 7 декабрендәге 416-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә тарифларны дәүләт тарафыннан җайга салу турында» 2013 елның 13 маендагы 406 номерлы, «2022 елның 1 декабреннән 2023 елның 31 декабренә кадәр җайга салына торган бәяләрне (тарифларны) индексацияләү үзенчәлекләре турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2022 елның 14 ноябрендәге 2053 номерлы карарлары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә җайга салына торган тарифларны исәпләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 27 декабрендәге 1746-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 2022 елның 15 ноябрендәге 36-ПР номерлы утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Менделеевск муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалыгы идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе (алга таба – «Менделеевск муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалыгы идарәсе» МУП) өчен эчә торган суга әлеге карар кушымтасына туры китереп тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар 2022 елның 1 декабреннән гамәлгә кертелә.

3. Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы «Менделеевск муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалыгы идарәсе» муниципаль унитар предприятиесенә ирекле файдаланылырга тиешле мәгълүматны Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2013 елның 17 гыйнварындагы 6 номерлы карары белән расланган Су белән тәэмин итү һәм ташландык су агызу өлкәсендә мәгълүмат ачу стандартлары нигезендә,

чираттагы җайга салу чорына тарифлар билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 30 календарь көннән соңга калмыйча ачарга.

4. Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитетының «Менделеевск муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалыгы идарәсе» муниципаль унитар предприятиесе өчен эчәргә яраклы суга һәм агынты суларны транспортлауга 2022 елга тарифлар билгеләү турында» 08.12.2021 № 470-137/кс-2021 карарының кушымтасындагы таблицаның түбәндәге графаларын 2022 елның 1 декабреннән көчен югалткан дип танырга:

| «01.01.2022 башлап 30.06.2022 кадәр | 01.07.2022 башлап 31.12.2022 кадәр |
|---|---|
| 24,13 | 25,60 |
| 25,68 | 26,91 |
| 37,34 | 39,03 |
| 24,13 | 25,60». |

5. Әлеге карар 2022 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла, дип билгеләргә.

6. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач гамәлгә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
15.11.2022 № 404-120/кс-2022
карарына кушымта

Салкын су белән тәэмин итүне гамәлгә ашыручы
«Менделеевск муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалыгы идарәсе» МУП өчен
2023 елга эчәргә яраклы суга тарифлар

| т/с | Муниципаль берәмлек, салкын су белән тәэмин итүне һәм (яки) ташландык су агызуны гамәлгә ашыручы оешма атамасы | Эчә торган суга тариф (бер ставкалы), сум/куб.м |
|---|---|---|
| | Менделеевск муниципаль районы | |
| 1 | «Менделеевск муниципаль районы торак-коммуналь хуҗалыгы идарәсе» МУП* | |
| 1.1 | Абалач, Бәзәкә, Бөрешле, Енабердино, Камай, Монашево, Песәй, Иске Гришкино, Татар Чаллысы, Тойгуҗа, Турай авыл җирлекләре, Менделеевск шәһәренең «Тихие горы» микрорайоны кулланучылары | 27,90 |
| 1.2 | Тихоново авыл җирлеге кулланучылары | 29,31 |
| 1.3 | Монай авыл җирлеге кулланучылары | 42,54 |
| 1.4 | Ижевка авыл җирлеге кулланучылары | 27,90 |

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге